РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
30.04.2019

**КАРАР**
№ 364

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында” 2018 елның 25 сентябрендәге 853 карарын үтәү йөзеннән, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Кушымта итеп бирелгән өлешне расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә (2 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 нче пункты белән билгеләнгән хезмәт хакы хәзерге заман нигезендә хезмәткә түләүнең яңа шартларына күчкәндә, вазыйфаларның күләмен саклап калган очракта хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан да ким булырга тиеш түгел.

3. Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләренә:

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартларын билгеләүче коллектив килешүләргә, локаль норматив-хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләрен хезмәт шартлары үзгәрү турында хезмәт хакы түләү системасына үзгәрешләр кертү турындагы карар кабул итүгә кадәр ике айдан да соңга калмыйча кисәтергә кирәк.

4. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.Ф. Кирилинага йөкләргә.

**Җитәкче** **А. Б. Семенычев**